**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ МОРДОВСКО-АФОНЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКӘСЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423103, Мордва Афонькэсе авылы, Цаплин урамы, 19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru

**№ 135** **16.10.2024 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы**

## КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мордва Афонькәсе авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

- җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;
- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мордва Афонькәсе авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;
- әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мордва Афонькәсе авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мордва Афонькәсе
авыл җирлеге
Советы рәисе, башлыгы: А.И. Митяев